**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

422066, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. 8(84362) 41-6-47

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел. 8(84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
07.11.2018

КАРАР
№ 33

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге Советы тарафыннан
2012 нче елның 30 нче маенда кабул ителгән
13 нчы номерлы " Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл
җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә»
карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба районы прокуратурасының 2018 нче елның 9 нчы октябрендә кабул ителгән 02-08-04-267-18 нче номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Иске Икшермә авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ**:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл жирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән " Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә» карарының 20 нче булеген түбәндәге эчтәлекле 20.1.1 пункты белән тулыландырырга:

«20.1.1 Коррупциягә каршы тору максатларында әлеге Федераль закон белән билгеләнгән, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы "Коррупциягә каршы көрәш турында" Федераль законына һәм башка федераль законнар нигезләнеп, муниципаль хезмәткәрләргә чикләүләр һәм тыюларны, мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен, нигезләмәнең 20 п. каралган түләтүләр салына.

Түләтүләр эшкә алучы вәкил (эш бирүче) тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә кулланыла:

1) коррупциягә һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклады;

2) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү буенча комиссия тәкъдимнәрен һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу, әгәрдә тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад комиссиягә җибәрелгән очракта;

2.1) коррупциягә каршы профилактика буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе доклады Һәм коррупңион хокук бозулар турында башка хокук бозулар, анда аны кылган факттагы хәлләр килеп чыса һәм муниципаль хезмәткәрнең язма аңлатмасы һәм аның ризалыгы белән генә коррупциячел хокук бозу фактын тану шарты белән (түләтүдән тыш, ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү);

3) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмасы;

4) башка материаллар.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/ikshurma адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Нурмөхәммәтов